СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГОРАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта
Кирмән авылы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.: (85563) 2-92-38; e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 2-5 13 апрель 2026 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында " 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын танырга:

- 2021 елның 10 июнендәге 2-9 номерлы "Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында";

- 2022 елның 15 августындагы 3-17 номерлы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" ;

- 2017 елның 25 августындагы 1-23 номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының "Урта Кирмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне "Мамадыш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында”;

2. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча

http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /Б.Ф.Хасанов/